ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» марта 2026 ел № 55

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 сентябрендәге 256 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 03 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законны үтәү йөзеннән, «Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге булмаган автомобиль юллары исемлеген раслау өлешендә юл эшчәнлеге буенча Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» Әгерҗе муниципаль районы Советының 29.12.2022 елның 24-3 номерлы карары нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы автомобиль юллары исемлеген актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 сентябрендәге 256 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарда (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлеге) 2 нче кушымтаның 150 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Җирле | Керт | Кадас | Юлның | Озынлыгы, км | Мәйданы, кв. м. |
|---|---|---|---|---|---|---|

| Т/с | к, торак пункт, юл, урам исемнәре | ү елы: | тр номеры | идентификация номеры | Барлыгы | Шул исәптән | | | | Барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ц/б | а/б | щеб, грав. | грунт | | ц/б | а/б | щеб,грав. | грунт |
| Күләгәш авыл җирлеге | | | | | | | | | | | | | | |
| | **Күләгәш авылы** | | | | | | | | | | | | | |
| 150 | Совер урамы | 1950 | | 92-201-820 ОП МП 92-000 | 0,474 | | 0,160 | | 0,3147 | 2146,8 | | 888,0 | | 1258,8 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**